СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.08.2023 г. Заинск № 290

**«Зәй муниципаль районында территорияне планлаштыру проекты, территорияне ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру тәртибе турында нигезләмә хакында» 2018 елның 04 маендагы 289 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы карарына үзгәреш кертү турында»**

«Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законның 16 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацының үз көчен югалтуын тану хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закоп, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районы Советы

# КАРАР ИТТЕ:

1. «Зәй муниципаль районында территорияне планлаштыру проекты, территорияне ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру тәртибе турында нигезләмә хакында» 2018 елның 04 маендагы 289 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы карары белән расланган Зәй муниципаль районында территорияне планлаштыру проекты, территорияне ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру тәртибе турында нигезләмәнең 2.6 пунктына (Зәй муниципаль районы Советының 2021елның 8 декабрендәге № 187 номерлы карары белән кертелгәннәрне исәпкә алып),

«бер ай һәм өч айдан артык» сүзләрен «ундүрт көн һәм утыз көннән артык» сүзләренә үзгәртеп кертергә.

2. Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN. RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны экология, җир мәсьәләләре, төзелеш, ТКХ һәм транспорт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**